ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 64 от «15» 02 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 августында кабул ителгән 1028 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясы, 27 статьясы, 50 статьясы таләпләре һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 24, 26 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 августында кабул ителгән “Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 1028 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 2 статьясының 2.2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Гомуми файдаланудагы су объектларын куллану Россия Федерациясе Су кодексының 50 статьясы нигезендә расланган рекреацион максатларда су объектларын куллану кагыйдәләрен, шулай ук шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су объектларын куллану кагыйдәләрен исәпкә алып башкарыла.".

2. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль райоы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Х.Әгъләмовка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

00000122